**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 гыйнвар № 16

г. Казань

«Түбән Кама эретеп ябыштыру-монтаж көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең исемен «Түбән Кама күппрофильле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе дип үзгәртү турында

Квалификацияле кадрларны өзлексез һөнәри әзерләүне оештыру, төрле профильдәге программаларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, «Түбән Кама эретеп ябыштыру-монтаж көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе педагогик коллективының көллиятнең исемен «Түбән Кама күппрофильле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Түбән Кама күппрофильле көллияте) дип үзгәртү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Түбән Кама күппрофильле көллиятен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Түбән Кама күппрофильле көллиятендә укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

«Түбән Кама эретеп ябыштыру-монтаж көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе уставына;

Түбән Кама күппрофильле көллияте өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

3. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты

турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Түбән Кама күппрофильле көллияте уставына үзгәрешләр керткәннән соң һәм аларны раслаганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 9 ноябрь, 830 нчы карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\16.docx